**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**ул.Ленина, д.60,**
**с. Старый Мензелябаш, 423354**
**Телефон: (85559) 4-53-46**
**E-mail: Smnz.Sar@tatar.ru**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**Ленин урамы, 60 йорт,**
**Иске Минзәләбаш авылы, 423354**
**Телефон: (85559) 4-53-46**
**E-mail: Smnz.Sar@tatar.ru**

**ОКПО 93068290, ОГРН 1061687002442, ИНН/ КПП 1636005422/ 163601001**

---

«09» ноябрь 2018 ел №13

«Җәлилнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең 12 залежь скважиналарын төзекләндерү 2018 ел(2 этап)» линия объектына планлаштыру һәм территорияләрне межалау проектын карау буенча ачык тыңлауларны билгеләү турында

"Татнефть» ААҖ «Җәлилнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең 01.11.2018 ел №6268-ПОрг хаты, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46нчы маддәләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» №131-ФЗ законының 14, 15нче маддәләре, ТР Сарман муниципаль районы Уставы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге халкының муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукын тәэмин итү максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 28 маддәсенә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 маддәсенә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 маддәсенә таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Җәлилнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең 12 залежь скважиналарын төзекләндерү 2018 ел.(2 этап)» линия объектына планлаштыру һәм территорияләрне межалау проектын карау буенча 2018 елның 12 декабренә 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Ленин урамы, 58 йорт адресы буенча

урнашкан Сарман районының Иске Минзәләбаш авылы мәдәният йорты бинасында ачык тыңлауларны үткәрүне билгеләргә.

2. Территорияне планлаштыру буенча документлар проектындагы материалларның текст һәм график өлеше белән:

- http://sarmanovo.tatarstan.ru/ сайтында
- хакимият бинасында эш көннәрендә 8.00-17.00 сәгатьләрдә 12.12.2018 кадәр танышырга мөмкин.

3. Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Ленин ур., 58нче йорт адресы буенча урнашкан Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башкарма комитеты бинасын территорияне планлаштыру һәм межалау проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җыю урыны итеп билгеләргә.

4. Әлеге карарны норматив-хокукый актларны игълан итү өчен мәгълүмат стендында, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, httr://PRAVO.TATARSTAN.RU адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгы А. Р. Мияссаровага йөкләргә.

Иске Минзәләбаш
авыл җирлеге Башкарма
комитеты җитәкчесе

А.Р. Мияссәрова